**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**О внесении изменений в Указ Президента Республики Татарстан «О единовременной денежной выплате членам семей военнослужащих и лиц, проходивших службу в войсках национальной гвардии Российской Федерации, погибших (умерших) в результате участия в специальной военной операции, проводимой на территориях Донецкой Народной Республики, Луганской Народной Республики и Украины»**

В целях материальной поддержки членов семей военнослужащих, погибших (умерших) в результате непосредственного выполнения задачи по охране государственной границы Российской Федерации на участках, примыкающих к районам проведения специальной военной операции, а также членов семей сотрудников Управления Федеральной службы безопасности Российской Федерации по Республике Татарстан, органов внутренних дел Российской Федерации в Республике Татарстан (Министерства внутренних дел по Республике Татарстан), погибших (умерших) в результате участия в специальной военной операции или непосредственного выполнения задач, связанных с ее проведением, **постановляю**:

1. Внести в Указ Президента Республики Татарстан от 4 апреля 2022 года № УП-233 «О единовременной денежной выплате членам семей военнослужащих и лиц, проходивших службу в войсках национальной гвардии Российской Федерации, погибших (умерших) в результате участия в специальной военной операции, проводимой на территориях Донецкой Народной Республики, Луганской Народной Республики и Украины» (с изменениями, внесенными указами Президента Республики Татарстан от 7 июня 2022 года № УП-400 и от 31 августа 2022 года № УП-611) следующие изменения:

а) в наименовании слова «, проводимой на территориях Донецкой Народной Республики, Луганской Народной Республики и Украины» исключить;

б) в преамбуле слова «проводимой на территориях Донецкой Народной Республики, Луганской Народной Республики и Украины с 24 февраля 2022 года,» исключить;

в) пункт 1 после слов «с 24 февраля 2022 года,» дополнить словами «а также на территориях Запорожской области и Херсонской области с 30 сентября 2022 года (далее – специальная военная операция),»;

г) пункт 5 изложить в следующей редакции:

«5. Распространить действие настоящего Указа на членов семей следующих лиц:

граждан, добровольно выполнявших военные задачи в ходе специальной военной операции, погибших (умерших) в результате участия в специальной военной операции;

военнослужащих (в том числе военнослужащих органов федеральной службы безопасности), погибших (умерших) в результате непосредственного выполнения задачи по охране государственной границы Российской Федерации на участках, примыкающих к районам проведения специальной военной операции;

сотрудников Управления Федеральной службы безопасности Российской Федерации по Республике Татарстан, погибших (умерших) в результате участия в специальной военной операции или непосредственного выполнения задач, связанных с ее проведением;

сотрудников органов внутренних дел Российской Федерации в Республике Татарстан (Министерства внутренних дел по Республике Татарстан), погибших (умерших) в результате участия в специальной военной операции или непосредственного выполнения задач, связанных с ее проведением.».

2. Кабинету Министров Республики Татарстан привести свои акты в соответствие с настоящим Указом, а также принять иные решения, обеспечивающие его реализацию.

3. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Раис**
**Республики Татарстан** — **Р.Н. Минниханов**

АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН · ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РАИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
03 апреля 2023 года
№ 194

**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы һәм Украина территорияләрендә уздырыла торган махсус хәрби операциядә катнашулары нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләре хәрби хезмәткәрләренең һәм аларда хезмәт иткән затларның гаилә әгъзаларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

Махсус хәрби операция уздырыла торган районнарга тоташкан участокларда Россия Федерациясе дәүләт чиген саклау бурычларын турыдан-туры үтәүләре нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) хәрби хезмәткәрләрнең гаилә әгъзаларына, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашулары яисә аны уздыру белән бәйле бурычларны турыдан-туры үтәү нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Татарстан Республикасында Россия Федерациясе эчке эшләр органнары (Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы) хезмәткәрләре гаилә әгъзаларына матди ярдәм күрсәтү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы һәм Украина территорияләрендә уздырыла торган махсус хәрби операциядә катнашулары нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләре хәрби хезмәткәрләренең һәм аларда хезмәт иткән затларның гаилә әгъзаларына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү турында» 2022 елның 4 апрелендәге ПУ-233 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2022 елның 7 июнендәге ПУ-400 номерлы һәм 2022 елның 31 августындагы ПУ-611 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) атамасында «Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы һәм Украина территорияләрендә уздырыла торган» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) преамбулада «2022 елның 24 февраленнән Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы һәм Украина территорияләрендә уздырыла торган» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 1 пунктта «территорияләрендә» сүзеннән соң «, шулай ук Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә 2022 елның 30 сентябреннән (алга таба – махсус хәрби операция)» сүзләрен өстәргә»;

г) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Әлеге Указның гамәле даирәсенә түбәндәге затларның гаилә әгъзаларын кертергә:

махсус хәрби операция барышында ирекле рәвештә хәрби бурычлар үтәгән, махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның;

махсус хәрби операция уздырыла торган районнарга тоташкан участокларда Россия Федерациясе дәүләт чиген саклау бурычларын турыдан-туры үтәүләре нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) хәрби хезмәткәрләрнең (шул исәптән федераль куркынычсызлык хезмәте органнары хәрби хезмәткәрләренең);

Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең ук махсус хәрби операциядә катнашулары яисә аны уздыру белән бәйле бурычларны турыдан-туры үтәү нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) хезмәткәрләренең;

Татарстан Республикасында Россия Федерациясе эчке эшләр органнарының (Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының) махсус хәрби операциядә катнашулары яисә аны уздыру белән бәйле бурычларны турыдан-туры үтәү нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) хезмәткәрләренең.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына үз актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган башка карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2023 ел, 03 апрель
№ 194